**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИНН 1627005426 КПП162701001 ОГРН 1061674006426**
ул. Центральная, д.4, д.Псеево, Менделеевский район, Республика Татарстан, 423646
Тел. (факс): (85549) 3-71-22, e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**18.02.2025** **№ 1**

Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару
тыела торган урыннарны билгеләү
һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге
яшәү урыннарына кайтару турында карар
кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге Уставы нигезендә. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә хуҗаларыннан башка хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген расларга.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәтгалеев Вилдан Илсур улын йорт хуҗаларыннан башка хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Песәй авыл җирлеге » бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Песәй авыл җирлеге башлыгы В.И. Мөхәммәтгалеев

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Песәй авыл җирлеге
Башкарма комитетының 18 фералендәге 1нче
номерлы карарына 1 кушымта

Песәй авыл җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗаларыннан
башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

Хайваннарны приютта стерильләштерү , тамгалау, исәпкә алу, карантинлаштыру, дәвалау, вакцинацияләү чаралары тәмамланганнан соң, башка хайваннарга яисә кешегә карата мотивацияләнмәгән агрессивлык күрсәтми торган хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына(тотылган ау урынына) кире кайтару тыела, әгәр мондый хайваннарны приютларда, территориядә һәм территорияләрдән 500 метрдан якынрак ераклыкта тоту мөмкинлеге булмаса:

- балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.
- җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).
- мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.
- мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.
- җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары янындагы территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектлары урнашкан урыннар.
- йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.
- күпфатирлы йортларга якын территорияләр, аларда урнашкан, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, моңа күпфатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары да керә.
- Зиратлар һәм мемориаль зоналар.